ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 29 апрелендәге 1876 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 1 бүлегендәге 7 абзацы; «2013—2017 елларга Казан шәһәренең аварияле торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары редакциясендә); «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.С. Кокурова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

Казан шәһәре 2018 елның 14 ноябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка В.С. Кокурова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья Э.М. Мостафина мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.С. Кокурова түбәндәгеләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының

2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 29 апрелендәге 1876 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 1 бүлегендәге 7 абзацы;

«2013—2017 елларга Казан шәһәренең аварияле торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары редакциясендә);

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары.

Ләкин 2018 елның 30 октябрендә гражданка В.С. Кокурова Татарстан Республикасы Конституция судына үз шикаятен кире алу турында гариза белән мөрәҗәгать итте.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

Мөрәҗәгать итүче үз шикаятен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы кире алганга күрә, әлеге шикаять буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 72 статьясына һәм 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 29 апрелендәге 1876 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 1 бүлегендәге 7 абзацы; «2013—2017 елларга Казан шәһәренең аварияле торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары редакциясендә); «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге 7992 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5206 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка В.С. Кокурова шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүченең әлеге шикаятьне кире алуы сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка В.С. Кокуровага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 33-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**